ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2019 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап хакында

2019 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Хисап палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

финанс-икътисадый вәзгыять начарлану куркынычы шартларында Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчаларыннан файдалануны тикшереп торуны гамәлгә ашырганда чыгымнарның нәтиҗәлелеген һәм аларны экономияләүне бәяләү мәсьәләләренә, нәтиҗәсез чыгымнарны профилактикалау чараларына аеруча игътибар итүне;

законнарда каралган эш рәвешләрен кулланып, Татарстан Республикасында илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны тикшереп торуны тәэмин итүне;

Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына һәм шушы программалардагы үзгәрешләргә финанс-икътисад экспертизасы үткәрү, программа чараларының максатчан индикаторларына ирешүне анализлау эшен дәвам итүне;

Татарстан Республикасында бюджет процессына, дәүләт милкенә идарә итүгә һәм аның белән эш итүгә тышкы дәүләт финанс тикшереп торуын камилләштерү эшен дәвам итүне.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2020 елның 23 апреле
№ 394-VI ДС